**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево
422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевский урамы, 23 нче йорт
Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

**2021 елның 25 гыйнвары** **82 номер**

## КАРАР

**Кадастр номерлары16:24:160303:978, 16:24:160303:977 булган җир кишәрлекләре белән чикләнгән территорияне планлаштыру проектын әзерләү турында.**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставы нигезендә, планлаштыру структурасы элементларын бүлеп бирү, гомуми файдаланудагы территорияләр чикләрен, капиталь төзелеш объектларын планлаштырып урнаштыру зоналары чикләрен билгеләү, территорияне планлаштырыла торган үстерүнең характеристикасын һәм чиратлылыгын билгеләү максатыннан, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Олы Кабан авыл җирлеге, Олы Кабан авылы адресы буенча урнашкан кадастр номерлары 16:24:160303:978, 16:24:160303:977 булган җир кишәрлекләре белән чикләнгән территорияне планлаштыру проектын әзерләргә.

2. Территорияне планлаштыру проектын әзерләү вакытын -2021 елның 31 гыйнварына кадәр билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Интернет-телекоммуникация челтәрендә Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында http://laishevo/tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көннән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп тору Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары И.П. Шитовка йөкләнә.

Район Башкарма комитеты
җитәкчесе А.А. Новиков